




РӘШИТ ХӘЙРЕТДИНОВ

«КамАЗ» КИЛӘ

Бар халыклар тыңлый ил сулышын,
Яңгырыйлар горур авазлар —
Мең йөрәкнең иркә баласыдай
Конвейерда килә «ҚамАЗ»лар.

Машиналар тулган заводларны
Зәңгәр экраннардан күзләрсез;
Анда безнең дус та эшли,— диеп,
Бәлки, шул чак мине эзләрсез.

Ә мин монда үзәк конвейерны
Һәр көн бер әйләнми түзмимен,
Уңганнарның данлы хезмәтенә
Тиңдәш ялкын сүзләр эзлимен.

Максатыбыз үзе берләштергән
Граниттан ныклы кыя без.
Дөньякүләм данлы заводларда
Илгә машиналар җыябыз.

Ә «ҚамАЗ»лар
Мең чакрымнар буйлап
Тоткарлыксыз узып кайдан да,
— Без дә съезд делегаты,— диеп,
Туктадылар Кызыл мәйданда.

125

**Рәшит Хәйретдинов.**

“КамАЗ” килә.

Бар халыклар тыңлый ил сулышын,

Яңгырыйлар горур авазлар-

Мең йөрәкнең иркә баласыдай

Конвейерда килә “КамАЗ”лар.

Машиналар тулган заводларны

Зәңгәр экраннардан күзләрсез;

Анда безнең дус та эшли,- диеп,

Бәлки, шул чак мине эзләрсез.

Ә мин монда үзәк конвейерны

Һәр көн бер әйләнми түзмимен,

Уңганнарның данлы хезмәтенә

Тиңдәш ялкын сүзләр эзлимен.

Максатыбыз үзе берләштергән

Граниттан ныклы кыя без.

Дөньякүләм данлы заводларда

Илгә машиналар җыябыз.

Ә “КамАЗ”лар

Мең чакрымнар буйлап

Тоткарлыксыз узып кайдан да,

Без дә съезд делегаты,-диеп,

Туктадылар кызыл мәйданда.